| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.04.2018 г.Лениногорск № 421

Лениногорск муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлек юнәлеше буенча Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының тәртип саклау буенча җәмәгать пункты хезмәткәрләренең вазыйфаи инструкцияләрен раслау турында

Җәмәгать иминлеген, шул исәптән юл хәрәкәте иминлеген һәм транспорт куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ Федераль законның 6 статьясына, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауның җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге № 33-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 06 октябрендәге, № 131-ФЗ Федераль законның 15 һәм 16 статьяларына таянып, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда», «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының баш белгече вазифаи инструкциясен Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль берәмлеге территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге эшчәнлек юнәлеше буенча (1 нче кушымта);

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының тәртип саклау буенча җәмәгать пунктының әйдәп баручы белгече

вазыйфаи инструкциясен Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль берәмлеге территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек юнәлеше буенча (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының тәртип саклау буенча җәмәгать пункты белгече эш вакытының регламенты юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек юнәлеше буенча (эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә урамнарда, транспорт магистральләрендә, вокзалларда, аэропортларда һәм башка урыннарда хезмәт вазыйфаларын башкарганда) (3 нче кушымта);

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының тәртип саклау буенча җәмәгать пункты белгече эш вакытының регламенты юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлек юнәлеше буенча (эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә урамнарда, транспорт магистральләрендә, вокзалларда, аэропортларда һәм башка урыннарда хезмәт күрсәтүләргә бәйле булмаган хезмәт бурычларын үтәгәндә) (4 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Лениногорские вести» рәсми публикатор-газетасында бастырып чыгарырга һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче Н.Р. Залаков

И.Р.Хәйбрахманов
5-44-72